КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 июль г.Казань № 533

2020 – 2022 елларда «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында «Кванториум» күчмә технопаркларын оештыру чараларын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын тормышка ашыру, «Мәгариф» илкүләм проекты буенча проект комитеты утырышының 2018 елның 7 декабрендәге 3 номерлы беркетмәсе белән расланган «Һәр баланың уңышы» федераль проектының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында төбәк проектлары паспортларын раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 30 март, 254 нче карары редакциясендә) максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә (шул исәптән «Кванториум» күчмә технопарклары (авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә яшәүче балалар өчен) оештырылды» дигән 1.12 нче нәтиҗәгә) ирешү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын 2020 – 2022 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында «Кванториум» күчмә технопаркларын оештыру чараларын тормышка ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елда «Кванториум» күчмә технопаркларын оештыру буенча чаралар комплексын («юл картасы»н);

2021 – 2022 елларда «Кванториум» күчмә технопаркларын оештыру буенча чаралар комплексын («юл картасы»н);

Оештырыла торган «Кванториум» күчмә технопарклары тасвирламасын.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин